Кукмара муниципаль районы
Починок Кучук авыл җирлеге Советы

КАРАР

2022 елның 9 сентябре № 20

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

49 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасының 3 абзацында «муниципаль торак фондын яшәү өчен яраксыз» сүзләрен «муниципаль һәм шәхси торак фондын яшәү өчен яраксыз, барлык торак урыннары Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, күпфатирлы йортлар авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Починок-Кучук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Р. Ә. Гыйниятов